**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 апрель № 259

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү тәрәзәсе.»;

1.13 нче пунктка «җибәрелергә» сүзе алдына «, шулай ук административ регламентны раслаган дәүләт хакимияте башкарма органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга» сүзләрен өстәргә;

1.15 нче пункттагы «шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарында» сүзләрен «шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган килгән кешеләр күрерлек урыннарда» сүзләренә алыштырырга;

2.2 нче пунктның «в» пунктчасында «күпфункцияле үзәкләрдә» сүзләреннән соң «, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында» сүзләрен өстәргә;

2.3 нче пунктның «в» пунктчасында:

икенче абзацтагы «дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең» сүзләреннән соң «, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәккә караган читтәге эш урыннарының» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дәүләт хезмәтләре күрсәтү урыннарындагы стендларда түбәндәге мәгълүматны урнаштыруга карата таләпләр:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы күрсәтә торган дәүләт хезмәтенең исеме;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе тасвирнамәсе;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты (әгәр туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралса);

г) законнар яки башка норматив хокук актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында үтенеч, моңа Россия Федерациясе законнарында документлар бирүнең ирекле формасы каралган очраклар керми), шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле гариза бирүче кертергә тиешле документларның тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны кертү тәртибе;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге;

е) дәүләт пошлинасы яки дәүләт хезмәте күрсәткән, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләттерелә торган башка түләү күләме;

ж) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының эш вакыты турында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы белгечләренең дәүләт хезмәте күрсәтү хакында гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүмат;

з) дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар өчен аларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларга һәм гамәлләргә (гамәлләр кылмауга) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

хокуклары булу турында мәгълүмат;»;

2.4 нче пунктның «п» пунктчасындагы «дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә» сүзләреннән соң «, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында» сүзләрен өстәргә;

2.5 нче пунктта:

беренче абзацтагы «күпфункцияле үзәкләрдә» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «үз эченә алырга тиеш» сүзләре алдына «, техник хаталарны (хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү процедурасын тасвирлауны» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\259.docx